УДК 930.2 DOI: 10.22378/he.2018-3-2.326-333

# «СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫНДА ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ ШӘХЕСЕНЕҢ ЯКТЫРТЫЛЫШЫ (1915 ЕЛ)

***А.Ә. Зиннәтуллина***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*jamash.00@mail.ru*

Тәкъдим ителгән мәкаләдә «Сөембикә» журналының Ш.Мәрҗанинең тууына һиҗри ел хисабы белән 100 ел тулуга багышланган махсус саны тикшерелә. Хезмәттә галимнең шәкертләре истәлекләре, аның исемен мәңгеләштерү максатыннан чыгып ясалган тәкъдимнәр, XX гасыр башында төрле өлкәдә хезмәт куйган татар зыялыларының фикерләре урын алган. Журналда басылып чыккан мәкалә авторлары күзлегеннән чыгып, Ш.Мәрҗанинең хатын-кыз мәсьәләсенә карата булган фикер юнәлешен ачыкларга талпыныш ясала.

**Төп төшенчәләр:** хәзрәт, Ш.Мәрҗани, татар матбугаты, мәдрәсә, хатын-кызлар, Казан, Бохара, «Сөембикә» журналы.

Билгеле булганча, татар җәмәгатьчелеге арасында Ш.Мәрҗанинең тууына һиҗри ел хисабы белән 100 ел тулу уңаена багышланган хәзерлек эшләре 1912 елда ук башлана. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1915 елда галимнең тәрҗемәи хәлен, хезмәтләрен, хатларын, аның турында истәлекләрне үз эченә алган «Мәрҗани» мәҗмугасы дөнья күрә. Әлеге җыентык Ш.Мәрҗани эшчәнлегенең әһәмиятен, аның турында тулы мәгълүматны халыкка таратуда һәм бүгенге көнгә кадәр саклап калуда зур роль уйный.

1915 елда Ш. Мәрҗанинең тууына 100 ел тулу уңаеннан күп кенә эшләр башкару күздә тотыла. Мәсәлән: галимнең каберенә зиярәт кылу, мәчетләрдә Мәрҗани рухына дога һәм аңа багышлап Коръән уку, аның эшчәнлеге турында төрле лекцияләр сөйләү һ.б. шундый эшләр. Ләкин дата Беренче бөтендөнья сугышы вакытына туры килү сәбәпле, зур тантаналар ясалмый, бәйрәм тыйнак кына үтеп китә [3, 39 б.].

Ш. Мәрҗани юбилее уңаеннан галимне искә төшерү, укучыларга аны таныту максаты белән татар вакытлы матбугаты битләрендә күпсанлы мәкаләләр басылып чыга. Мәсәлән, 1915 елның гыйнвар аенда гына Мәрҗанигә бәйле булган 40ка якын мәкалә дөнья күрә [3, 41 б.], ә «Сөембикә» журналының гыйнвар саны исә тулысы белән диярлек галимгә багышлана. Әлеге санда барлыгы 10 язма басылып, шуларның 7се Мәрҗанигә нисбәтле.

Журналның эчтәлегенә килгәндә, ул «Сөембикә»нең нашире һәм мөхәррире булаган Якуб Хәлилинең «Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләре» [7] дип исемләнгән мәкаләсе белән башланып китә. Анда автор укучыларны Мәрҗанинең кыскача гына тәрҗемәи хәле белән таныштыра, аның атасы мәдрәсәсендә уку елларын, соңыннан шунда ук шәкертләргә дәрес бирә башлавын сурәтли. Мәдрәсәләрдәге уку-укыту системасыннан риза булмыйча, шул ук вакытта белемен арттыру максаты белән Бохарага китүен, беренче елларда зур матди авырлыклар кичереп, Бохарада укуын, андагы дәресләргә канәгатьсезлек белдереп, күбрәк вакытын китапханәләрдә уздыруын сөйли. Нәкъ менә шул китапханәләрнең галимгә уңай йогынты ясавына һәм аның фикере формалашуга булышлык итүнә басым ясый. Мәкаләдә шулай ук Мәрҗанинең Казанга килүе, имам-хатыйп булуы һәм мөдәррислек итүе тасвирлана.

Якуб Хәлили әлеге мәкаләсендә Ш.Мәрҗанине, дингә нык бирелгән булса да, алдынгы карашлы, тотынган эшен ахырына кадәр җиткерүче, чиста-пөхтә, аз сүзле, киңкырлы галим буларак искә ала.

Мәрҗани турында булган хатирәләрне үз эченә алган икенче бер күләмле мәкалә Әхмәдзәки Вәлидинең «Мәрҗани хакында кечкенәлегемдә язган бәгъзе нәрсәләрем мөнәсәбәте илә» [2] язмасы.

Ә.-З. Вәлиди бала вакытында Үтәк авылы мөдәррисе, әнисе белән бер туган абыйсы Хәбибеннаҗар хәзрәт карамагында тәрбияләнә. Әлеге хәзрәт Мәрҗанинең иң яхшы шәкертләреннән берсе, күпмедер вакыт Мәрҗани мәдрәсәсендә укыткан, галим белән дустанә мөнәсәбәттә була. Әлеге хәзрәт ярдәмендә Ә.-З. Вәлиди беренче тапкыр Мәрҗани һәм аның хезмәтләре белән таныша, Хәбибеннаҗар хәзрәтне Мәрҗанинең дөньяга карашына, «күп кенә гыйлеменә варис булып калган кеше» дип кабул итә, шул сәбәпле үзен дә Мәрҗани шәкерте дип саный.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, Хәбибеннаҗар хәзрәтнең Мәрҗани турында булган кайбер истәлекләре «Мәрҗани Мәҗмугасы»нда да урын алган [5, 469–485 б.].

Ә.-З. Вәлидинең башкалардан ишеткән әһәмиятлерәк сүзләрне, хикәяләрне дәфтәргә язып бара торган гадәте була. Ул Мәрҗани турында Хәбибеннаҗар хәзрәт һәм күрше авылдан Шәфигъ ахун сөйләгән истәлекләрне дә язып алган була һәм журналга тәкъдим ителгән мәкаләсендә алардан өзекләр китерә.

Ә.-З. Вәлиди мәкаләсендә тәкъдим ителгән беренче истәлек Хәбибеннаҗар хәзрәт тарафыннан сөйләнеп, Мәрҗанинең үлер алдындагы халәтен тасвирлый. Хәзрәт Мәрҗанинең бик авыр хәлдә булуын, шул хәлдә дә фәнни эшен ташламавын әйтә. «Миңа “Мөстәфадел-әхбар”ның икенче җилдендән кайбер бүлекләрен хәзерләү эшен тапшырды. Семипулат һәм Сәгыйть бистәләре хакында кайбер мәгълүмат тупларга боерды», – ди [2, 10 б.]. Мәрҗани хәзрәтләре авырган чагында «Бер ел буена йоклый алмас булды. Бәгъзе вакыт йокы килгән кеби булыр иде, дәрес вакытында мендәр сорар һәм башын куеп торыр, ләкин йоклый алмас иде», – ди [2, 10 б.].

Мәрҗанинең чәй эчәргә яратуын искә алып, түбәндәгеләрне сөйли: «Иң хуп күргән мәҗлесе мәдрәсә мәҗлесе иде. Ничә самавырлар бетәр иде. Чәйне бик яратып эчәр иде. Шәкертләр дамеллага бәлеш пешереп кул илә ашамакка чакырырлар иде. Рәхәтләнеп ашар иде. Башыннан чалмалары, түбәтәйләре төшеп китәр иде» [2, 10 б.].

Хәбибеннаҗар хәзрәт тагын бер вакыйганы исенә төшереп: «Үзем бервакыт тир авыруы илә авырдым. Хәзрәт һәркөн ике-өч мәртәбә ишектән башын тыгып, «Нихәл мелла Наҗар, тазармыйсыңмы әле?», – дип сорай торган иде. Бераз төзәлгәч, бүлмәгә таягы белән таянган хәлдә кереп торды һәм «Йә, мелла Наҗар, чәчне алаек», – диде. Аның чәчен күп вакыт мин ала идем, җылы су илә юып та торган идем. Башы зур иде, тигез иде. […] Менә шул вакытта ул күп сүзләр сөйләшә иде», – ди [2, 10 б.].

Мәкаләдә алга таба Ә.-З. Вәлиди Шәфигъ ахунны искә төшерә. Ул Мәрҗани белән хат язышкан кеше һәм, китаплары чыгу белән аларны Мәрҗани әлеге ахунга җибәрә торган була. «Бик хәтеремдә, – дип яза автор, – бер вакыт мин Шәфигъ ахунны үзебезгә кунакка алырга бардым. Кыш көне иде. Ахун хәзрәткә ихтирамым бик зур булганга, ул кешене кысрыкламас өчен, чананың читенә генә утырып бардым. Ул миңа күп сүзләр сөйләде […] сөйли-сөйли барып миңа әйтә иде: «Углым, инде шул Мәрҗани кебек булсаң иде» [2, 11 б.]. Ә.-З. Вәлиди үзенең «убежденный семинарист» булуына карамастан, ахун артыннан: «Ярабби, Мәрҗани кебек булсам иде», [2, 11 б.] – дип теләгәнен искә ала. Димәк, Мәрҗанинең фикер юнәлеше һәрвакыт актуаль булып калган.

Ә.-З. Вәлидинең алга таба язган истәлекләрендә исә, Мәрҗанинең укыту ысуллары тикшерелә. Анда Мәрҗанинең, гәрчә Бохара уку-укыту тәртибен яратмаса да, бу замандагы мохитнең йогынтысы нәтиҗәсендә дәресләрен Бохара өслүбендә алып барырга мәҗбүр булуы искәртелә. Шулай булмаган очракта, ягъни Мәрҗани дәресләрен үзе теләгәнчә алып барса, үзенең планнарын тормышка ашыра башласа, бөтен дөньяны иске караш чорнап алган чорда аңа берәр шәкерт килер идеме соң? – дигән сорау куела.

Дөрестән дә, Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә эшчәнлек иске тәртиптә алып барылган, ләкин яңалыклар, дөньяви фикерләр галим тырышлыгы белән шәкертләр арасына үтеп кергән. Мәдрәсә эчендә география, тарих һәм башка фәннәр белән чынлап шөгыльләнүчеләр булган. Әлеге мәдрәсәдән чыккан шәкертләрнең рус уку йортларында укулары, күбесенең алдынгы карашлы муллалар булып китүләре моның ачык дәлиле булып тора.

Мәрҗанинең тәрҗемәи хәлен, аның карашларын, әйләнә-тирә мохитнең галимгә булган мөнәсәбәтен яктырткан тагын бер мәкалә «Шиһаб хәзрәт» дип атала [8]. Мәкаләнең авторы – Шәриф Хөсәенов. Әлеге мәкалә Г. Тукайның галимгә багышлап язылган «Шиһаб хәзрәт» шигыре белән башланып китә һәм өч өлештән тора.

Беренче өлештә автор Мәрҗани заманында схоластик күзаллауларның хөкем сөрүенә, дөньяви белемгә омтылучыларның юк дәрәҗәсендә

булуына, Россия мөселманнарының Бохара тәртипләре буенча яшәвенә басым ясый.

Мәкаләнең икенче өлеше Мәрҗанигә багышлана. Бу мәкаләдә, галимгә багышланган күпчелек язмалардагы кебек үк, татар җәмәгатьчелегенең Мәрҗанигә булган мөнәсәбәте, галимнең беренче тапкыр Казанга килүе, Казан руханилары һәм башка югары дәрәҗәдәге кешеләрдән торган мәҗлестә имтихан тотуы, үзенең күпчелектән аерылып торган карашлары, башкача фикерләве аркасында каршылыкларга очравы чагылыш таба.

«Сөембикә» журналы, эчтәлеге белән татар хатын-кызлары өчен иң актуаль булган мәсьәләләрне яктыртып барырга тиешле махсус басма буларак, әлбәттә, Ш. Мәрҗанинең хатын-кызга булган мөнәсәбәтен дә чагылдырырга тырышкан. Шәриф Хөсәенов мәкаләсенең өченче өлешендә шушы мәсьәләне ачыкларга тырыша. Автор: «Мәрҗанине […] чолгаган мохитка караганда аңардан хатын-кыз хакында хәзерге фикер ияләре карашын үк көтү, әлбәттә, урынсыздыр», – дип белдерә [8, 22 б.]. Ләкин аның бу мәсьәләдә замандашларыннан шактый югары торганлыгын, хөррият тарафында булганлыгын ассызыклый. Сүзләрен дәлилләп, автор Мәрҗанинең үз хатыннарын сердәш, фикердәш, булышчы итеп күрүен, кызларының гыйлемле остазбикәләр булуларын мисал итеп китерә.

Мәрҗанинең хатын-кыз мәсьәләсендә хөр фикердә, аларны гыйлемле, белемле итү теләгендә булуын дәлилләгән тагын бер мисал югарыда әйтеп узган Я. Хәлили мәкаләсендә чагылыш таба. «Бер вакыт [Мәрҗани. – *З.А.*] хатын-кызларны алып мәҗнүннәр йортына барды. Шундагы назир һәм җәмәгатьләре белән күрешеп утырыштылар. Шундан кайтканда кызларына карап: “Менә аларның кызлары өч-дүрт төрле тел белүләре өстенә музыкалар да өйрәнәләр. Сез дә дөм сукыр, дөм гафил булмагыз, иң азында бер-ике төрле язу өйрәнегез” дип кызларны үгетләмештер», – ди [7, 7 б.].

Хатын-кыз мәсьәләсен яктырткан тагын бер язма – Чыгътайның «Шиһабетдин әл-Мәрҗани хакында фикерләр» [9] мәкаләсе. Бу мәкаләдә шулай ук «Мәрҗани хатын-кыз мәсьәләсендә ни эшләде?», «Бу мөһим мәсьәләне ул игътибарга алдымы?», «Бу заманда ул берәр сүз сөйләдеме? дигән сораулар куела [9, 18 б.]. Мәкаләнең эчтәлегеннән чыгып, әлбәттә, ул заманда, хәтта ир-егетләргә дә дөньяви белемнәрне бик зур саклык белән генә бирергә тырышкан вакытта, Мәрҗани, бәлки, хатын-кызлар турында бик уйламагандыр да, уйласа да, әлегә вакыт җитмәгәнен аңлап, тыелып торгандыр. Ләкин, истәлекләрдән күренгәнчә, Мәрҗани үзен әйләндереп алган кыз туганнары белән яхшы мөнәсәбәттә булган, хатын-кызлар алдында үзен кутәренке һәм горур тотмаган, аларга яшьләренә туры китереп кызык сүзләр сөйләгән, аларның буш вакытларын кызыклы һәм файдалы үткәрергә, үзендә булган мәгълүматлардан хәбәрләр биреп торырга тырышкан, дигән нәтиҗә чыгарырга була.

Шулай итеп, Ш.Мәрҗани хатын-кыз мәсьәләсен ачык яктыртмаса да, турыдан-туры аңа игътибар бирмәсә дә, күңеленнән хатын-кызларның

гыйлемле, ирекле, дөрес фикер йөртүче шәхес булуларын теләгән, дисәк, ялгыш булмас.

Чыгътайның журналга тәкъдим ителгән мәкаләсендә, хатын-кыз мәсьәләсеннән тыш, Ш. Мәрҗани турындагы кайбер башка фикерләр тупланып бирелгән. Алар арасында К. Тәрҗемани, Г. Баруди кебек дин эшлеклеләре, Ә.-Һ. Максуди кебек газета-журнал мөхәррирләре, Ф.Әмирхан, Ә.-З. Вәлиди кебек яшь зыялылар һәм заманы өчен алдынгы башка шәхесләрнең фикерләре бар. Алар галимгә һәрберсе үзе өчен якын булган өлкәдән чыгып бәя биргән. Мәсәлән, Г. Баруди аны күренекле дин һәм гыйлем эшлеклесе, Ә.-Һ. Максуди татар милли аңын уяткан исляхчы мөгаллим һәм мөдәррис дип мактый, Баттал – мәгънәви хакыйкать эзләүче, Гыйсмәти – коллык дәверен бетерүче дип саный. Ләкин кем генә булмасын, барысы да галимне мактап искә ала.

Журнал битләрендә, әлбәттә, алдынгы карашлы татар хатын-кызларының мәкаләләре дә урын ала. Шундыйларның берсе – 1914 елдан журналның сәркатибе булып эшләгән Фәхрелбанат Сөләймания мәкаләсе [6]. Автор үз мәкаләсендә хатын-кызларны, Мәрҗанинең исемен мәңгеләштерү максатыннан чыгып, берәр хәерле эш эшләргә чакыра һәм бу уңайдан үзенең тәкъдимен дә җиткерә. Ул, сугышта һәлак булган татар гаскәриләренең балаларын тәрбияләү өчен, Ш.Мәрҗани исемендәге ятимханә ачу уңышлы булыр иде дип саный.

Икенче мәкаләнең авторы – алдынгы карашлы мөгаллимә Мәһруй Мозаффария [4]. Автор Ш. Мәрҗанине бриллиант белән чагыштыра, һәм Мәрҗани, Гаспринский, Тукай кебек олуг шәхесләрнең мирасын саклап калырга, аларның тәрҗемәи хәлләрен, әсәрләрен тулысы белән яшь буынга җиткерергә кирәклегенә басым ясый. Шул вакытта гына яшь буын бу олуг шәхесләрнең бәясен белер, ди.

Журналда, Мәрҗанигә багышланган истәлекләрдән тыш, Ш.Мәрҗанинең ике рәсеме һәм Шәһид Әхмәдиевның фантастик жанрда язылган «Юбилей көне» исемле хикәясе урын алган [1].

Йомгак ясап әйткәндә, Ш.Мәрҗанинең тәрҗемәи хәлен, эшчәнлеген, аның турында кызыклы истәлекләрне халыкка таратуда вакытлы матбугат әһәмиятле урын алып торган. «Сөембикә» журналында да Ш. Мәрҗани турында кызыклы һәм бай мәгълүмат тупланган. Әлеге мәкаләләр ярдәмендә без Ш.Мәрҗани шәхесе белән тагын да якыннанрак танышу белән беррәттән, ул яшәгән чор мохитын, галимне әйләндереп алган вәзгыятьне кузаллый алабыз. Мәкалә авторлары төрле булуга карамастан, алар берберсен кабатламыйлар. Һәрбер мәкаләдә авторның Ш. Мәрҗани шәхесенә карата булган ихтирамы, аның белән горурлану хисе сизелеп тора.

## ӘДӘБИЯТ

1. Әхмәдиев Ш. Юбилей көне // Сөембикә. 1915. № 6. Б. 12–15.

2. Вәлиди Ә.-З. Мәрҗани хакында кечкенәлегемдә язган бәгъзе нәрсәләрем мөнәсәбәт илә // Сөембикә. 1915. № 6. Б. 8–12.

3. Миңнуллин Җ. Ш. Мәрҗанинең 100 еллыгын бәйрәм итү // Мәрҗани: тарих һәм хәзерге заман. Мәкаләләр җыентыгы. Казан: Мастер Лайн, 1998. Б. 39–43.

4. Мозаффария М. Мөхтәрәм Шиһабетдин хәзрәт // Сөембикә. 1915. № 6. Б. 19–20.

5. Мөхәммәдкяфи М. Мәдхәл // Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2010. Б. 469–485.

6. Сөләймания Ф. Татар хатын-кызлары дикъкатенә // Сөембикә. 1915. № 6. Б. 7–8.

7. Хәлили Я. Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләре // Сөембикә. 1915. № 6. Б. 2–7.

8. Хөсәенов Ш. Шиһаб хәзрәт // Сөембикә. 1915. №6. Б. 20–23.

9. Чыгътай Г.М. Шиһабетдин әл-Мәрҗани хакында фикерләр // Сөембикә. 1915. № 6. Б. 15–19.

**Автор турында белешмә:** Зиннәтуллина Алсу Әнвәр кызы – фәнни хезмәткәр, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин ур., 7а йорт, Казан, Россия Федерациясе); jamash.00@mail.ru

## ОСВЕЩЕНИЕ ЛИЧНОСТИ ШИГАБУТДИНА МАРДЖАНИ НА СТРАНИЦАХ ЖУРНАЛА «СЮЮМБИКЕ» (1915)

***А.А. Зиннатуллина***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*jamash.00@mail.ru*

В статье анализируется специальный номер журнала «Сююмбике», посвященный 100-летнему юбилею по хиджри известного ученого-историка, религиозного и общественного деятеля Шигабутдина Марджани. В работе нашли отражение воспоминания его учеников, предложения по увековечиванию памяти ученого, сделана попытка определения отношения ученого к женскому вопросу.

**Ключевые слова:** хазрат, Ш.Марджани, национальная периодическая печать, медресе, женский вопрос, Казань, Бухара, журнал «Сююмбике».

**Для цитирования:** Зиннәтуллина А.Ә. «Сөембикә» журналында Шиһабетдин Мәрҗани шәхесенең яктыртылышы (1915 ел) // Историческая этнология. 2018. Т. 3, № 2. С. 326–333. DOI: 10.22378/he.2018-3-2.326-333

**Сведения об авторе:** Зиннатуллина Алсу Анваровна – научный сотрудник, Центр истории и теории национального образования, Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); jamash.00@mail.ru

## COVERAGE OF SHIHAB AL-DIN AL-MARJANI'S PERSONALITY IN "SYUYUMBIKE" MAGAZINE (1915)

***A.A. Zinnatullina***

*Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*jamash.00@mail.ru*

The paper describes a special issue of the Syuyumbike magazine, dedicated to the 100th anniversary AH of a well-known scholar-historian, religious and public figure, Shihab al-Din al-Marjani. The article contains memories of his shakirds, suggestions to perpetuate the memory of the scholar, and an attempt to define the scholar's attitude to the issue of women.

**Keywords:** hazrat, Shihab al-Din al-Marjani, national periodicals, madrasa, women's issue, Kazan, Bukhara, Syuyumbike magazine.

**For citation:** Zinnatullina A.A. Coverage of Shihab al-din al-Marjani's personality in "Syuyumbike" magazine (1915). *Istoricheskaya etnologiya – Historical Ethnology*, 2018, vol. 3, no. 2, pp. 326–333. DOI: 10.22378/he.2018-3-2.326-333

## REFERENCES

1. Ähmädiev Sh. Jubilej köne [The Anniversary Day]. *Söembikä – Syuyumbike*, 1915, no. 6, pp. 12–15. (In Tatar)

2. Välidi Ä.-Z. Märçani hakynda kechkenälegemdä jazgan bägze närcälärem mönäcäbäte ilä [On some of the things I've written about Marjani in my childhood]. *Söembikä – Syuyumbike*, 1915, no. 6, pp. 8–12. (In Tatar)

3. Miñnullin Ç. Sh. Märçanineñ 100 ellygyn bäräm itü [Celebrating the 100th anniversary of Sh. Marjani]. *Märçani: tarih häm häzerge zaman* [Marjani: Heritage and Modernity]. Kazan, Master Layn Publ., 1998, pp. 39–43. (In Tatar)

4. Mozaffariya M. Möhtäräm Shihabetdin häzrät [Dear Shihabutdin hasrat]. *Söembikä – Syuyumbike*, 1915, no. 6, pp. 19–20. (In Tatar)

5. Möhämmädkyafi Ỉ. Mädhäl [Introduction]. *Märçani: Fänni-populyar çyentyk* [Marjani: popular scientific collection of papers]. Kazan, Jien Publ., 2010, pp. 469–485. (In Tatar)

6. Söläjmaniya F. Tatar hatyn-kyzlary dikkatenä [To the attention of the Tatar women]. *Söembikä – Syuyumbike,* 1915, no. 6, pp. 7–8. (In Tatar)

7. Hälili Ya. Shihabetdin al-Märçani häzrätläre [Hasrat Shihab al-Din al-Marjani]. *Söembikä – Syuyumbike,* 1915, no. 6, pp. 2–7. (In Tatar)

8. Hösäenov Sh. Shihab häzrät [Shihab häzrät]. *Söembikä – Syuyumbike,* 1915, no. 6, pp. 20–23. (In Tatar)

9. Chygtay G.M. Shihabetdin al-Märçani hakynda fikerlär [Thoughts on Shihab al-Din al-Marjani]. *Söembikä – Syuyumbike,* 1915, no. 6, pp. 15–19. (In Tatar)

**About the author:** Alsou A. Zinnatullina is a Research Fellow, the Center of History and Theory of National Education, Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A, Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); jamash.00@mail.ru